**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6345**
**27.09.2024**

Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең балалар коллективлары арасында «XXI гасыр йолдызчыклары» муниципаль конкурсын оештыру һәм үткәрү турында

Башкарма комитетның 2021 елның 29 октябрендәге 7116 номерлы Карары белән расланган «2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын үтәү йөзеннән, яшь талантларны ачыклау, мәктәпкәчә яшьтәге балаларның музыкаль сәләтен ачу, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре педагогларының һәм балаларның игътибарын мәдәниятне үстерү һәм Татарстан Республикасы халыкларының мәдәни-тарихи мирасын саклау, эстетик тәрбия бирү мәсьәләләренә җәлеп итү максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның мәгариф идарәсенә мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең балалар коллективлары арасында «XXI гасыр йолдызчыклары» муниципаль конкурсын (алга таба – конкурс) үткәрергә.

2. Расларга:

1) конкурс үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурска әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурсны оештыру һәм үткәрү буенча чыгымнарны финанслауга акча бүлеп бирүне «Мәгариф өлкәсендә башка мәсьәләләр» 0709 бүлеге (бүлекчәсе) буенча 2024 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары хисабына 50 000 (илле мең) сум күләмендә тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка,  Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 27 сентябрендәге
6345 номерлы карарына
1 нче кушымта

Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең балалар коллективлары арасында «XXI гасыр йолдызчыклары» муниципаль конкурсын үткәрү турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «XXI гасыр йолдызчыклары» муниципаль конкурсы (алга таба – конкурс) Яр Чаллы шәһәрендә яшь талантларны ачыклау, мәктәпкәчә яшьтәге балаларның музыкаль сәләтен ачу, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре (алга таба – МББУ) педагогларының һәм балаларның игътибарын мәдәниятне үстерү һәм Татарстан Республикасы халыкларының мәдәни-тарихи мирасын саклау, эстетик тәрбия бирү мәсьәләләренә җәлеп итү максатларында үткәрелә.

2. Конкурсның тематикасы: «Бәхетле балачак», «Балалар бакчасы – яраткан йортым», «Минем дус гаиләм», «Минем яраткан тәрбиячем», «Минем туган ягым», «Милли мәдәният һәм традицияләр».

3. Конкурсның төп бурычлары булып тора:

1) мәктәпкәчә яшьтәге балалар арасында талантларны ачыклау һәм үстерү;

2) Татарстан Республикасының күпмилләтле мәдәнияте традицияләрен саклау һәм үстерү;

3) балаларга сәнгать-эстетик тәрбия бирү буенча МББУ эшен камилләштерү;

4) МББУ коллективларының иҗат дәрәҗәсен күтәрү, җыр һәм бию репертуарын киңәйтү;

5) балалар өчен стильләштерелгән концерт костюмнарын әзерләү дәрәҗәсен арттыру;

6) конкурста җиңүчеләрнең шәһәр чараларында катнашуы.

2 бүлек. Конкурсны оештыру

4. Конкурста шәһәрнең МББУның балалар коллективлары катнаша.

5. Кандидатларны конкурста катнашуга тәкъдим итү МББУ тарафыннан гамәлгә ашырыла (һәр МББУдан бер иҗади номер).

6. Конкурсны оештыручылар булып Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Яр Чаллы шәһәренең «Шатлык» 1 нче балалар бакчасы – баланы үстерү үзәге» муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе һәм составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты тора.

7. Оештыру комитеты жюри составын формалаштыра.

3 бүлек. Конкурсны үткәрү тәртибе

8. Конкурс өч турда үткәрелә.

9. I тур 2024 елның 30 октябренә кадәр МББУда үткәрелә.

II тур – сайлап алу, аерым график буенча 2024 елның 13 ноябреннән 2024 елның 15 ноябренә кадәр «1 нче шәһәр балалар һәм яшьләр иҗат сарае» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесенең концерт залында үткәрелә.

III тур – конкурсның финалы 2024 елның 26 ноябрендә конкурсантларның чыгышларын карау юлы белән үткәрелә.

10. Конкурста катнашу өчен катнашучының чыгышын әзерләргә кирәк:

1) татар, рус телләрендә һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрендә балалар җыры;

2) татар, рус телләрендә һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрендә шигырь;

3) классик, заманча бию, Татарстан Республикасы һәм дөнья халыкларының биюләре;

4) оригиналь жанр.

11. Балалар чыгышын бәяләүнең төп критерийлары:

1) артистлык һәм сәхнә культурасы;

2) башкару осталыгы;

3) җырның, шигырьнең музыкаль бизңлеше, эчтәлеге балаларның яшенә туры килү;

4) иҗади номерларга репетиция ясалу;

5) костюмнарның эстетикалы булуы;

6) иҗади номерның тамашалылыгы;

7) микрофоннан файдалана белү;

8) интонациянең, дикциянең чисталыгы һәм аваз әйтелешенең дөреслеге;

9) концерт номерының оригинальлеге.

12. Җыелган баллар нәтиҗәләре буенча III турда катнашучыларның гомуми санының яртысы финалга уза.

13. Конкурста җиңүчеләрнең гала-концерты 2024 елның 5 декабрендә 10.00 сәгатьтә «1 нче балалар һәм яшьләр иҗат сарае» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесенең концертлар залында үткәрелә.

## 4 бүлек. Конкурска йомгак ясау

14. Конкурста түбәндәге номинацияләр буенча I, II, III урыннар бирелә:

1) нәфис сүз;

2) вокал;

3) иң яхшы бию коллективы;

4) оригиналь жанр;

5) яшь башкаручы.

15. Конкурста катнашучылар әлеге нигезләмәнең 11 пунктында билгеләнгән критерийлар нигезендә биш баллы система буенча жюри әгъзалары тарафыннан бәяләнә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә. Жюри утырышы – ябык. Жюри карары беркетмә белән рәсмиләштерелә.

16. Конкурста җиңүчеләр дипломнар һәм истәлекле призлар белән бүләкләнә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева